КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 28 февраль г.Казань № 120

Татарстан Республикасында инвалидларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм иткәндә озатып йөрүне оештыру тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасында инвалидларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм иткәндә озатып йөрүне оештыру тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 28 февраль, 120 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасында инвалидларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм иткәндә озатып йөрүне оештыру
тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы (алга таба - 565-ФЗ номерлы Федераль закон), «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясындагы 3 өлеше, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларга дәүләт ярдәме чараларын күрсәткәндә махсус чараларны гамәлгә ашыру буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2024 елның 12 ноябрендәге 614 номерлы боерыгы нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасында инвалидларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар системасының бер өлеше булган инвалидларны озатуны оештыру тәртибен билгели.

2. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр 565-ФЗ номерлы Федераль законда кулланыла торган мәгънәләрдәге кебек кулланыла.

3. «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба - Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге) эш эзләүче инвалидка, аны эшкә урнаштырган вакытта, инвалидны тернәкләндерүнең яисә абилитацияләүнең индивидуаль программасындагы аның тормышындагы чикләүләр турында тәкъдимнәрне исәпкә алып, индивидуаль ярдәм күрсәтә.

4. Инвалидларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм иткәндә Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан озата бару инвалидларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм иткәндә озата баруны оештыру тәртибенә, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) составына, эзлеклелегенә, башкару срокларына, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә инвалидларны эш белән тәэмин итүдә озатып йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек стандартын раслау турында» 2022 елның 28 мартындагы 174н номерлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә инвалидларны эш белән тәэмин итүдә озатып йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек стандарты белән билгеләнгән процессларны тәэмин итүгә таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Инвалид Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә мөрәҗәгать иткәндә, инвалидны туры килә торган эш эзләүнең, халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт чаралары һәм сервислар алуның, Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә хезмәтләр алуның барлык этапларында озатып йөрүче персональ карьера консультанты беркетелә.

6. Инвалидларга аларның эш урынына кадәр бару һәм кире кайту юлын формалаштыруда ярдәм, шулай ук мондый ихтыяҗ булганда озата бару буенча башка чаралар инвалидка индивидуаль ярдәм күрсәтүче дәүләтнеке булмаган оешмалар тарафыннан, инвалидларның гомумроссия, төбәкара, республика һәм җирле иҗтимагый берләшмәләрен дә кертеп, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы яисә Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белән төзелә торган шартнамәләр нигезендә озату рәвешендә күрсәтелергә мөмкин.

7. Инвалидларны эшкә урнаштыру барышында күрсәтелә торган аларга хезмәт күрсәтүнең (чараларның) сыйфатын арттыру максатларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән дәүләтнеке булмаган оешмаларны хезмәттәшлеккә җәлеп итү, алар белән килешүләр һәм шартнамәләр төзү, «Россиядә эш» эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформада күрсәтелгән оешмалар реестрын тулыландыру буенча эш башкарыла.

___________________